**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**15.10.2018** **№ 2231**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының «2017-2020 елларга Биектау муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» максатчан программасын раслау турында» 2017 елның 19 октябрендәге 2605 номерлы карары белән расланган «2017-2020 елларга Биектау муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» максатчан программасына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 30 апрелендәге 289 номерлы (2018 елның 30 мартындагы ред.) «2014 - 2020 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының «2017-2020 елларга Биектау муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» максатчан программасын раслау турында» 2017 елның 19 октябрендәге 2605 номерлы карары белән расланган «2017-2020 елларга Биектау муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» максатчан программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Кушымтаның 3 пунктындагы беренче абзацында «федераль ярдәмче программасы» сүзләрен «федераль дәүләт программасы» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 21 пунктта:

беренче абзацта «1 августтан 1 сентябрьгә кадәр» һәм «1 сентябрьгә кадәр» сүзләрен «1 майдан 1 июньгә кадәр» һәм «1 июньгә кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «1 августта» сүзләрен «1 майда» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 26 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гариза һәм җыелма исемлек билгеләнгән срокларда Ярдәмче программаның дәүләт заказчысы тарафыннан федераль дәүләт программасының җаваплы башкаручысына тапшырыла.»;

1.4. 27 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«27. Планлаштырылган (агымдагы) елга Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган субсидия күләмен федераль дәүләт программасын җаваплы башкаручы тарафыннан билгеләгәннән соң һәм планлаштырыла торган (агымдагы) елга Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган субсидия күләме турында белешмәләрне Ярдәмче программаның дәүләт заказчысына җиткергәннән соң җыелма исемлек нигезендә һәм федераль бюджеттан бирелә торган субсидияләр күләмен, тиешле елга Татарстан Республикасы бюджетында һәм (яисә) җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре күләмен исәпкә алып, ярдәмче программалар чараларын финанслашу өчен, ә, торак кредитлары һәм заемнар бирә торган оешмалардан тыш, ярдәмче программаны гамәлгә ашыруда катнашучы оешмалар тарафыннан бирелә торган акчалар булганда, - күрсәтелгән акчаларны исәпкә алып, Ярдәмче программаның дәүләт заказчысы тиешле елда социаль түләүләр алуга дәгъва кылучы яшь гаиләләрнең исемлеген раслый.»;

1.5. 29 пунктның 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«29. Федераль дәүләт программасы чараларын финанслашуга каралган федераль бюджет чаралары Татарстан Республикасы бюджетында һәм (яисә) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларында кирәкле күләмдә федераль дәүләт программасы чараларын финанслауга акчалар каралган шарт белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән төзелгән килешү нигезендә федераль дәүләт программасын җаваплы башкаручы тарафыннан расланган килешү нигезендә бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм чыгымнарны финанслау күләмнәре чикләрендә федераль дәүләт программасын җаваплы башкаручы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына күчерелә.»;

1.6. 51 пунктның дүртенче абзацына түбәндәге эчтәлекле сүзләр өстәргә:

«, шулай ук күрсәтелгән документларның күчермәләрен.»;

1.7. 52 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«52. Җирле үзидарә органы банктан җирле бюджеттан акчаларны күчерүгә заявка алган көннән алып 10 эш көне эчендә банк счетына аны социаль түләү алу хокукы турында бирелгән таныклыклар хакындагы мәгълүматларга туры килүенә тикшерә һәм, тәкъдим ителгән документларның әлеге Кагыйдәләргә туры килү шарты белән, банкка социаль түләү сыйфатында бирелә торган акчаларны күчерә. Социаль түләү алуга хокук турында бирелгән таныклыклар турындагы белешмәләр заявкага туры килмәгәндә йә тапшырылган документлар әлеге Кагыйдәләргә туры килмәгәндә, күрсәтелгән акчаларны күчерү башкарылмый, бу хакта җирле үзидарә органы күрсәтелгән срокта банкка язмача хәбәр итә.»;

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча игълан итәргә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/. веб-адресы буенча урнаштырырга.

Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Р.Р. Сабирҗанов